ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 6 » мая 2022 ел № 82

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звеносы турында" Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының 2020 елның 13 августындагы 84 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 18 декабрендәге 860 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звеносы турында» 2020 елның 13 августындагы 84 номерлы Арча муниципаль районы башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звеносы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Арча муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Район башлыгы И.Г.Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ
ИНН 1609009523

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы башлыгының
6. 05. 2022 ел, №82
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галимуллин Илшат Әхәтович | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Вафина Эльвира Шамилевна | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, эвакокомиссия рәисе; |
| Шаһиәхмәтов Радик Дамирович | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, тотрыклы икътисад эшчәнлеге комиссиясе рәисе; |
| Юзаев Искәндәр Илнарович | - янгын сүндерү гарнизоны башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Шәрипова Гөлнар Рәшитовна | - «Арча муниципаль районының Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе, комиссия секретаре (килешү буенча); |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Баһавиев Айдар Рашатович | - Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Идрисов Ришат Илшатович | - «Арча район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының баш табибы (килешү буенча); |
| Нурмөхәммәтов Нияз Фәритович | - Идел буе электр челтәрләре «Сетевая компания» ачык акционерлар җәмгыяте филиалының Арча РЭСы башлыгы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Сафин Рөстәм Роальдович | - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Арча муниципаль районы буенча эчке эшләр бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Хәйруллин Шамил Мәхмүтович | - «Арча урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенең җитәкче-урманчысы (килешү буенча); |
| Сафиев Альберт Тәлгатович | - «Татавтодор» ачык акционерлар җәмгыятенең Арча филиалы директоры (килешү буенча); |
| Салкова Эльвира Валентиновна | - Татарстан Республикасының Арча районындагы (Арча) баш дәүләт санитар табибы урынбасары (килешү буенча); |
| Миндубаев Тәлгать Җәүдәтович | - «Тепло-сервис», «Водоканал-сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Сабиров Илшат Әнәсович | - «Сабыгаз» ЭПУ башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Касыймов Ленар Әдехәмович | - Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Төньяк территориаль идарәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Гыймадиев Рәшит Таһирович | - Ростехнадзорның Идел буе идарәсе өлкән дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Кадыйров Роберт Минзаһирович | - Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең (Арча муниципаль районы буенча) әйдәп баручы консультанты (килешү буенча); |
| Фәйзрахманов Рамил Рәшитович | -«Россия ВНГның Татарстан Республикасы буенча идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы-Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Таһиров Руслан Мансурович | - Арча «Таттелеком» гавами акционерлар җәмгыяте башлыгы (килешү буенча); |